ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23 сентябрь, 2020 ел № 1/12

Шәһәр Советының 2018 елның 24 апрелендәге «Даими рәвештә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең һәм Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүче затларның хезмәтенә түләү системасы турында» 24/6 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең айлык акчалата түләүләре һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы Карары, шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы:

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2018 елның 24 апрелендәге «Даими рәвештә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең һәм Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүче затларның хезмәтенә түләү системасы турында» 24/6 номерлы Карарына (Шәһәр Советының 2018 елның 10 августындагы 26/14 номерлы Карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 2 пунктның 1 пунктчасында «11 163» санын «11 498» санына алыштырырга;

2) 1 нче кушымтада:

- 16 пунктта түбәндәге эчтәлекле унҗиденче абзац өстәргә:

«Әлеге Карар белән билгеләнгән вазыйфаи оклад күләмен арттырганда, муниципаль хезмәт вазыйфалары буенча еллык акчалата керем аермасын тигезләү өчен айлык түләү күләме 2018 елның 31 мартына булган түләү күләменә туры килә һәм индексацияләнергә тиеш түгел.»;

- 18 пунктның 1 пунктчасында 7 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

7 нче таблица

Вазыйфаи окладлар күләме

| Вазыйфаның исеме | Арттыру коэффициенты, (процент) | Вазыйфаи оклад күләме (сумнарда) |
|---|---|---|
| Башкарма комитетның идарә, башка структур бүлекчәсе составындагы бүлек башлыгы | 1,78 | 20 467 |
| Сектор мөдире | 1,73 | 19 892 |
| Баш белгеч | 1,66 | 19 087 |
| Әйдәп баручы белгеч | 1,52 | 17 477 |
| 1 категорияле белгеч | 1,35 | 15 523»; |

- 19 пунктта түбәндәге эчтәлекле дүртенче абзац өстәргә:

«Әлеге Карар белән билгеләнгән вазыйфаи оклад күләмен арттырганда, техник тәэмин итү хезмәт вазыйфалары буенча еллык акчалата керем аермасын тигезләү өчен айлык түләү күләме 2018 елның 31 мартына булган түләү күләменә туры килә һәм индексацияләнергә тиеш түгел.»;

3) 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2 нче кушымта

Шәһәр Хакименә, муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасарына, Контроль-хисап палатасы Рәисенә айлык акчалата түләү күләме

| Вазыйфаның исеме | Айлык акчалата түләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Шәһәр Хакиме | 38 010 |
| Муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары | 34 209 |
| Контроль-хисап палатасы Рәисе | 34 209 |

4) 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

3 нче кушымта

Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләгәндә кулланыла торган арттыру коэффициентлары һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәре

| Вазыйфаның исеме | Арттыру коэффициенты, (процент) | Вазыйфаи окладларның күләме (сумнарда) |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | 3,26 | 37 484 |
| Шәһәр Хакиме (Шәһәр Советы) аппараты җитәкчесе;<br>Шәһәр Хакиме (Шәһәр Советы) аппаратының эшләр идарәчесе;<br>Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары;<br>Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары;<br>Башкарма комитетның район хакимияте башлыгы | 3,16 | 36 334 |
| Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе<br>Башкарма комитетның эшләр идарәчесе | 3,08 | 35 414 |
| Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе урынбасары;<br>Башкарма комитетның эшләр идарәчесе урынбасары<br>Контроль-хисап палатасы Рәисе урынбасары | 2,76 | 31 735 |
| Шәһәр Хакиме (Шәһәр Советы) аппараты идарәсе башлыгы;<br>Башкарма комитет идарәсе башлыгы;<br>Контроль-хисап палатасы идарәсе башлыгы;<br>Башкарма комитетның район хакимияте башлыгының беренче урынбасары;<br>Башкарма комитетның район хакимияте башлыгы урынбасары; | 2,30 | 26 446 |
| Башкарма комитетның башка структур бүлекчәсе җитәкчесенең беренче урынбасары; | 2,12 | 24 376 |

| | | |
|---|---|---|
| Шәһәр Хакиме (Шәһәр Советы) аппараты идарәсе башлыгының беренче урынбасары;<br>Башкарма комитет идарәсе башлыгының беренче урынбасары;<br>Шәһәр Хакиме (Шәһәр Советы) аппараты идарәсе башлыгы урынбасары;<br>Башкарма комитет идарәсе башлыгы урынбасары;<br>Контроль-хисап палатасы идарәсе башлыгы урынбасары | | |
| Шәһәр Хакиме (Шәһәр Советы) аппаратының мөстәкыйль бүлеге башлыгы (мөдире);<br>Башкарма комитетның мөстәкыйль бүлеге җитәкчесе (мөдире);<br>Шәһәр Хакиме (Шәһәр Советы) аппаратының башка структур бүлекчәсе җитәкчесе;<br>Башкарма комитетның башка структур бүлекчәсе җитәкчесе;<br>Контроль-хисап палатасының мөстәкыйль бүлеге башлыгы (мөдире);<br>Контроль-хисап палатасы аудиторы | 2,21 | 25 411 |
| Башкарма комитетның район хакимияте аппараты җитәкчесе | 2,29 | 26 331 |
| Шәһәр Хакиме (Шәһәр Советы) аппаратының мөстәкыйль бүлеге башлыгы (мөдире) урынбасары;<br>Башкарма комитетның мөстәкыйль бүлеге җитәкчесе (мөдире) урынбасары;<br>Башкарма комитетның башка структур бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары;<br>Контроль-хисап палатасының мөстәкыйль бүлеге башлыгы (мөдире) урынбасары; | 1,82 | 20 927 |
| Яр Чаллы шәһәре Хакиме ярдәмчесе; | 1,78 | 20 467 |

| | | |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе ярдәмчесе;<br>Яр Чаллы шәһәре Хакиме киңәшчесе;<br>Башкарма комитет Җитәкчесе киңәшчесе;<br>Башкарма комитетның идарә, башка структур бүлекчәсе составындагы бүлек башлыгы<br>Башкарма комитетның район хакимияте бүлеге башлыгы<br>Контроль-хисап палатасы идарәсе составында бүлек башлыгы | | |
| Башкарма комитетның идарә, башка структур бүлекчәсе составындагы сектор башлыгы<br>Башкарма комитетның мөстәкыйль бүлеге составында сектор мөдире;<br>Контроль-хисап палатасы идарәсе составындагы сектор мөдире;<br>Контроль-хисап палатасының мөстәкыйль бүлеге составындагы сектор мөдире;<br>Башкарма комитетның идарә, башка структур бүлекчәсе составындагы бүлек башлыгы урынбасары;<br>Башкарма комитетның район хакимияте бүлеге башлыгы<br>Контроль-хисап палатасының мөстәкыйль секторы мөдире | 1,73 | 19 892 |
| Шәһәр Хакиме (Шәһәр Советы) аппаратының идарә, бүлек, башка структур бүлекчәсе баш белгече;<br>Башкарма комитетның идарә, бүлек, сектор, башка структур бүлекчәсе баш белгече;<br>Контроль-хисап палатасының идарә, бүлек, секторы баш белгече;<br>Контроль-хисап палатасы аппараты баш инспекторы | 1,66 | 19 087 |

| | | |
|---|---|---|
| Шәһәр Хакиме (Шәһәр Советы) аппаратының идарә, бүлек, башка структур бүлекчәсе әйдәп баручы белгече;<br>Башкарма комитетның идарә, бүлек, сектор, башка структур бүлекчәсенең әйдәп баручы белгече;<br>Контроль-хисап палатасының идарәсе, бүлеге, секторы баш белгече;<br>Контроль-хисап палатасы аппаратының әйдәп баручы инспекторы | 1,52 | 17 477 |
| Шәһәр Хакиме (Шәһәр Советы) аппаратының идарә, бүлек, башка структур бүлекчәсенең 1 категорияле белгече;<br>Шәһәр Хакиме (Шәһәр Советы) аппаратының идарә, бүлек, башка структур бүлекчәсенең 2 категорияле белгече;<br>Шәһәр Хакиме (Шәһәр Советы) аппаратының идарә, бүлек, башка структур бүлекчәсе белгече;<br>Башкарма комитетның идарә, бүлек, сектор, башка структур бүлекчәсенең 1 категорияле белгече;<br>Башкарма комитетның идарә, бүлек, сектор, башка структур бүлекчәсенең 2 категорияле белгече;<br>Башкарма комитетның идарә, бүлек, сектор, башка структур бүлекчәсе белгече<br>Контроль-хисап палатасының идарә, бүлек, секторының 1 категорияле белгече,<br>Контроль-хисап палатасының идарә, бүлек, секторының 2 категорияле белгече,<br>Контроль-хисап палатасының идарә, бүлек, секторы белгече<br>Контроль-хисап палатасы аппараты инспекторы | 1,35 | 15 523 |

2. Әлеге Карар 2020 елның 1 октябреннән үз көченә керә.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев